Республика Татарстан
Совет Лякинского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Ләке авыл җирлеге
Советы

---

**РЕШЕНИЕ**
«10» апрель 2025 ел

**КАРАР**
№ 4

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә, Совет Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге **КАРАР ИТТЕ:**

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (1,2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын, аның график сурәтен дә кертеп, 2025 елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән (sarmanovo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге торак пунктлары территорияләрендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча:

Ләке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт;
Дружба авылы, Урман урамы, 2 а йорты;
Фермы Сәүкле авылы, Тукай урамы, 2 йорт.

3. Карар халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге советы рәисе Ю.Г.Антонов

10.04.2025 ел, № 4
Ләке авыл җирлеге
Советның карарына
1 нче кушымта

Ләке авыл җирлеге вәкиллекле органнарына депутатлар сайлау буенча бермандатлы сайлау округлары схемасы

| № п/п | Сайлау округы исеме | Округ чикләре | Сайлаучылар саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Ләке № 1 | **Ләке авылы**, Уңыш урамы, №№ 1-47; 2-34; йортлары; Яшьләр урамы, №№ 4,6,9,11 йортлар | 41 |
| 2 | Ләке № 2 | **Ләке авылы**, Тау башы урамы, №№ 1-20 йортлар; Яңа урам, №№ 1-5а йортлары | 44 |
| 3 | Ләке № 3 | **Ләке авылы,** Түбән оч урамы, №№ 1-22 йортлар; Яшьләр урамы, №№ 1,5,5а йортлар; **Языкәу авылы**, Пушкин урамы, № 2 йорт. | 40 |
| 4 | Ләке № 4 | **Ләке авылы**, Колман урамы, №№ 2-36; 13-23 йортлар. | 43 |
| 5 | Ләке № 5 | **Ләке авылы**, Колман урамы, №№ 1–11; 25; йортлар; Мәктәп урамы, №№ 1-6;йортлар Үзәк урам, №№ 1-12 йортлар | 43 |
| 6 | Ләке № 6 | **Ләке авылы**, Ямаш Игәнәй урамы, №№ 1-39; № 2-38 а йортлар. | 43 |
| 7 | Ләке № 7 | **Дружба авылы**, Урман урамы, №№ 1-25; 2-22, 32 йортлар; **Фермы Сәүкле авылы**, Тукай урамы, №№ 2-23 йортлар. | 48 |

# Лякинский УИК







